**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ ЖЭКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ**
**КАРАР**

**«1» июль 2021 ел** **№ 35**

Олы Җәке авыл җирлеге Советының 13.11.2019 ел, №173 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында (15.04.202020 ел, № 185 карар белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының "Олы Җәке авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Олы Җәке авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Олы Җәке авыл җирлеге Советының 13.11.2019 ел, №173 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә (15.04.202020 ел, №185 карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.7.1 пунктын түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

1.7.1. Гражданнар җыены торак пункт территориясе өлешендә торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелергә мөмкин.

Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясенең бер өлеше чикләре, җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләне хәл иткәндә, торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең гомуми мәнфәгатьләре критериеннән чыгып, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә.

1.2. 3.5 пунктта. «торак пунктта яшәүчеләр "сүзләреннән соң «(яисә аның территориясенең бер өлеше)" сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында халыкка игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru( Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталына Интернет челтәрендә) http://zelenodolsk.tatarstan.ru шулай ук Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Олы Яке авылы, Мәктәп урамы, 1 нче йорт (авыл җирлеге администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 1а йорт (Олы Җәке күпфункцияле үзәге бинасы), Каратмән авылы, Клуб урамы, 23 нче йорт (авыл клубы бинасы), Уразлы авылы, Подгорная урамы, 138 нче йорт (Уразлы авыл клубы) адреслары буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Олы Җәке авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе: Ф. А. Фәйзуллина